| МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.05.2016 г.Казань № 99/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2016 елның 15 гыйнварындагы “2016 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алына торган акчалар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” №1/2-пр боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 4 декабрендәге “Нәселле терлекчелеккә ярдәм итү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү турында” № 1257, 2012 елның 22 декабрендәге “Авыл хуҗалыгын иминиятләштерү шартнамәләре буенча иминиятләштерү премияләрен түләүгә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” № 1371 карарларын үтәү һәм законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2016 елның 15 гыйнварындагы “2016 елга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан алына торган акчалар хисабына субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” №1/2-пр боерыгына (16.02.2016 № 15/2-пр, от 13.04.2016 № 73/2-пр боерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба - Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Боерыкның 1.7 пунктын түбәндәге эчтәлектә бәян итәргә:

“1.7. 2016 елда нәселле терлекчелеккә, сөт һәм ит билгеләнешендәге нәселле мөгезле эре терлеккә ярдәм итүгә федераль бюджет акчалары хисабыннан субсидияләр бирү тәртибе (7 кушымта)”;

1.2. Боерыкның 7 кушымтасын яңа эчтәлегендә бәян итәргә (кушымта булып килә).

1.3. Боерыкка 8 кушымтада:

1 пунктны яңа эчтәлегендә бәян итәргә:

“1. Бу Тәртип үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгын иминиятләштерү шартнамәләре буенча һәм терлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгын иминиятләштерү шартнамәләре буенча иминиятләштерү премияләрен түләүгә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджет акчалары хисабыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) бирү механизмын билгели.”;

2 пунктның “б” пунктчасын түбәндәгечә бәян итәргә:

“б) авыл хуҗалыгы культураларын чәчү һәм (яки) күп еллык утыртмаларны утырту өчен чәчүлек кишәрлекләре булу (авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең авыл хуҗалыгы культураларының, шул исәптән күп еллык утыртмаларның уңышын (бөртекле, бөртекле-кузаклы, майлы, техник, терлек азыгы, бакча культураларын, бәрәңгене, яшелчәләрне, виноградлыкларны, җимешле, җиләкле, чикләвек утыртмаларын, колмак, чәй плантацияләрен), күп еллык утыртмаларны (виноградлыкларны, җимешле, җиләкле һәм чикләвекле утыртмаларны, колмак, чәй плантацияләрен) иминиятләштерү шартнамәләре буенча иминиятләштерү премияләрен түләүгә карата чыгымнарының бер өлешен каплаганда;”;

4 пунктның “а” пунктындагы беренче һәм икенче кызыл юлларны түбәндәгечә бәян итәргә:

“а) үсемлекчелек өлкәсендә - авыл хуҗалыгы культураларының уңышын (бөртекле, бөртекле-кузаклы, майлы, техник, терлек азыгы, бакча культураларын, бәрәңгене, яшелчәләрне, виноградлыкларны, җимешле, җиләкле, чикләвек утыртмаларын, колмак, чәй плантацияләрен), шул исәптән күп еллык утыртмаларның уңышын югалтканда (һәлак булганда), күп еллык утыртмаларны (виноградлыкларны, җимешле, җиләкле һәм чикләвекле утыртмаларны, колмак, чәй плантацияләрен) югалтканда, түбәндәге вакыйгалар килеп туган очракларды:

Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү өчен куркыныч булган табигый күренешләрнең йогынтысы (атмосфера, туфрак корылгы, коры җил, кырау, өшү, бурсып черү, боз сугу, тузанлы давыл, бозлы кабык, ташкын, су басу, язгы ташу, җир убылу, туфракның артык дымлы булуы, көчле җил, давыллы җил, җир тетрәү, кар ташкыны, сил, табигый янгын);”;

5 пунктта:

Дүртенче кызыл юлны түбәндәгечә бәян итәргә:

“авыл хуҗалыгын иминиятләштерү шартнамәсенең күчермәсен (шушы Тәртипнең 7 пунктындагы унберенче кызыл юлда каралган очракта, иминиятләштерү портфелен тапшыру турында шартнамәнең һәм тапшырылган авыл хуҗалыгын иминиятләштерү шартнамәләре исемлеген үз

эченә алучы иминиятләштү портфелен тапшыру-кабул итеп алу актының күчермәләре)”;

Алтынчы кызыл юлны түбәндәге төзәтмәсендә бәян итәргә:

“авыл хуҗалыгын иминиятләштерү шартнамәсен төзегәндә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә иминиятләштерүче оешма тарафыннан бирелгән һәм аның җитәкчесе таныклаган, Россия Федерациясе Үзәк Банкы билгеләгән тәртиптә исәпләп чыгарыла торган норматив күләмнән түләү мөмкинлегенең фактик күләмен арттыру турында иминиятләштерүче оешманың түләү мөмкинлеге турындагы хисаптан өземтәне, яисә авыл хуҗалыгын иминиятләштерү шартнамәсе буенча иминиятләштерү түләвенә кагыла торган куркыныч өлешендә иминиятләштерүче оешманы яңадан иминиятләштерү турындагы, шул исәптән яңадан иминиятләштерүче оешманың (яңадан иминиятләштерү оешмаларның) атамасы турындагы мәгълүматны, яңадан иминиятләштерүгә тапшырылган куркыныч (куркынычлар) буенча иминиятләштерү түләүләренең өлеше (күләме) турындагы белешмәләрне, яңадан иминиятләштерү шартнамәсенең (шартнамәләренең) реквизитларын (төзү датасын, шартнамәнең номерын, яңадан иминиятләштерү рәвешен) үз эченә алган документны.”;

6 пунктта:

“б” пунтчасын түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә:

“б) “Авыл хуҗалыгын иминиятләштерү өлкәсендә дәүләт ярдәме турында һәм “Авыл хуҗалыгын үстерү турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законның 6 статьясында каралган авыл хуҗалыгын иминиятләштерү планында (алга таба - хуҗалыгын иминиятләштерү планы) тиешле елга күрсәтелгән бер яки берничә төрле авыл хуҗалыгы культуралары уңышына карата, шул исәптән күп еллык утыртмаларның уңышына, күп еллык үлән утыртмаларының уңышына карата авыл хуҗалыгын иминиятләштерү шартнамәләрен төзү, - авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесе тарафыннан әлеге авыл хуҗалыгы культуралары һәм күп еллык утыртмалар үстерелә торган җир кишәрлекләренең барлык мәйданында;”;

“в” пункчасында “авыл хуҗалыгы терлекләренең баш саны” сүзләре алдыннан “бер яки берничә” сүзләрен өстәргә;

“з” пункчасын түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә:

“авыл хуҗалыгын иминиятләштерү шартнамәсендә шартсыз франшиза яки агрегатлы шартсыз франшиза билгеләү турында каралган булса, һәр авыл хуҗалыгы культурасына, күп еллык утыртмаларның төркеменә, авыл хуҗалыгы терлекләренең төренә, җенесенә, яшь составына карата

иминиятләштерү суммасының 30 процентыннан артмаган күләмдә франшиза билгеләү;”;

7 пунктта:

унберенче кызыл юлны түбәндәгечә бәян итәргә:

“Иминиятләштерү оешмасыннан аңа авыл хуҗалыгын иминиятләштерү хокукын бирә торган иминиятләштерү эшчәнлеген башкаруга карата лицензиясе алынган очракта, авыл хуҗалыгын иминиятләштерү шартнамәсе буенча мондый иминиятләштерү оешмасына максатчан акчаларны күчерү турындагы карарны кабул итү эше әлеге иминиятләштерү оешмасы авыл хуҗалыгын иминиятләштерү буенча төзелгән шартнамәләргә карата бурычларны (иминиятләштерү портфелен) башка иминиятләштерүче оешмага (башка иминиятләштерүче оешмаларга) тапшырганчыга кадәр, иминиятләштерү законнары нигезендә туктатылып тора. Шушы Тәртипнең 5 пунктындагы дүртенче кызыл юлында каралганча, Министрлык иминиятләштерү портфелен бирү турындагы шартнамәнең һәм тапшырылган авыл хуҗалыгын иминиятләштерү шартнамәләренең исемлеген үз эченә алучы кабул итеп алу-тапшыру актының күчермәләрен алганнан соң, авыл хуҗалыгын иминиятләштерү шартнамәләре буенча бурычларны кабул итеп алган иминиятләштерү оешмасының исәп-хисап счетына максатчан акчаларны күчерә.”.

2. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовны җаваплы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр

М.Г. Әхмәтов

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының 15.01.2016 № 1/2-пр боерыгы белән расланды (ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы редакциясендә)

# 2016 елда нәселле терлекчелеккә, сөт һәм ит билгеләнешендәге нәселле мөгезле эре терлеккә ярдәм итүгә федераль бюджет акчалары хисабыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип үсемлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгын иминиятләштерү шартнамәләре буенча һәм терлекчелек өлкәсендә авыл хуҗалыгын иминиятләштерү шартнамәләре буенча иминиятләштерү премияләрен түләүгә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре чыгымнарының бер өлешен каплауга федераль бюджет акчалары хисабыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр алуга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләрен сайлап алу критерийләре булып терлекчелек продукциясен җитештерү һәм сату тора.

3. Субсидияләр бирүнең шартлары булып түбәндәгеләр тора:

а) Россия Федерациясе субъекты территориясендә нәселле терлекчелек оешмаларының дәүләт нәселле терлекләр регистрында теркәлгән, нәселле терлекчелек буенча оешмалар булган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренеке булган нәселле терлекләргә ия булу (алга таба – дәүләт нәселле терлекләр регистрында теркәлгән нәселлек терлекләр);

б) Россия Федерациясе субъекты территориясендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең авыл хуҗалыгы терлекләргә ия булуы;

в) Россия Федерациясе субъекты территориясендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең иткә дигән, кимендә 500 баш эре мөгезле терлеккә ия булуы.

4. Арбитраж суд тарафыннан субсидияләр алучыларга карата бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылганда, алар (алучылар) бу хакта, эш кузгатылган көнне, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) язмача хәбәр итәргә тиеш.

Субсидияләр үзләренә карата арбитраж суды тарафыннан бөлгенлеккә төшү тарафыннан эш кузгатылган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелми.

5. Субсидияләр бирүнең максаты булып нәселле терлекчелеккә ярдәм итү, шул исәптән нәселле һәм гадәти терлекләрне үстерүне, үрчетүне һәм терлекләрне ясалма орлыкландыру колачын киңәйтүне тәэмин итү тора.

6. Субсидияләр авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә түбәндәге юнәлешләр буенча бирелә:

а) нәселле авыл хуҗалыгы ана терлекләрен асрау өлешендә нәселлек терлекчелеккә булышу, сөт яки ит юнәлешендәге нәселле эре мөгезле терлектән кала;

б) сөт юнәлешендәге нәселле мөгезле эре терлек асрауга ярдәм итү, шул исәптән:

сөт юнәлешендәге нәселле ана мөгезле эре терлекне асрау;

нәсел сыйфаты тикшерелгән яки әлеге сыйфатны бәяләү процессындагы, 16 айдан зуррак булган, сөт юнәлешендәге нәселле үгезләр (алга таба – сөт юнәлешендәге нәселле үгезләр) асрау;

терлекнең туган иле тарафыннан бирелгән геномын бәяләү нәтиҗәләре буенча сөт җитештерүчәнлекне һәм технологик сыйфатларны яхшыртучы сөт юнәлешендәге нәселле үгезләр, шул исәптән импорт буенча, сатып алу;

сөт юнәлешендә нәселле яшь мөгезле эре терлек сатып алу;

сөт юнәлешендә, шул исәптән җенесе буенча аерылган нәселле үгез орлыкларын сатып алу;

сөт юнәлешендәге мөгезле эре терлекнең яралгыларын (шул исәптән импорт буенча) сатып алу;

в) ит юнәлешендәге нәселле мөгезле эре терлек асрауга ярдәм итү, шул исәптән:

ит юнәлешендәге нәселле ана мөгезле эре терлекне асрау;

нәсел сыйфаты тикшерелгән яки әлеге сыйфатны бәяләү процессындагы, 16 айдан зуррак булган, итчелек юнәлешендәге нәселле үгезләр (алга таба – ит юнәлешендәге нәселле үгезләр) асрау;

ит җитештерүчәнлекне һәм технологик сыйфатларны яхшыртучы ит юнәлешендәге нәселле үгезләр, шул исәптән импорт буенча, сатып алу;

ит юнәлешендәге мөгезле эре терлекнең нәселле яшь терлекләрен сатып алу;

ит юнәлешендә нәселле үгез орлыкларын сатып алу.

7. Нәселле терлекчелеккә ярдәм итүгә акчалар Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югарыгы башкарма органы вәкаләт биргән орган (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан билгеләнелә торган ставкалар буенча түбәндәге максатларга, Россия Федерациясе субъектына күздә тотылган акчалар чикләрендә, бирелә:

а) Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланыла торган исемлеккә кертелгән авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең югарыгы башкарма органнары тәкъдиме белән, – 1 шартлы башка ставка буенча нәселле ана терлекләр асрауга (сөт һәм ит буенча терлекчелектә – хисап финанс елында тере бер бозау тудырган бер сыер исәбеннән). Нәселле ана терлекләрнең баш санын шартлы башка күчерү өчен коэффициентлар Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнелә;

б) Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан расланыла торган исемлеккә кертелгән терлекләрне ясалма орлыкландыру буенча оешмаларга, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең югарыгы башкарма органнары тәкъдиме белән, – бер башка ставка исәбеннән, ит һәм сөт юнәлешендәге нәселле үгезләр асрауга;

в) терлекләрне ясалма орлыкландыру буенча оешмаларга – дәүләт нәселле терлекләр регистрында теркәлгән ит һәм сөт юнәлешендәге нәселле үгезләр сатып алуга, шул исәптән импорт буенча, 1 кг тере авырлык ставкасы буенча;

г) авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләреннән – дәүләт нәселле терлекләр регистрында теркәлгән, сөтчелек һәм итчелек юнәлешләрендәге нәселле мөгезле яшь эре терлек сатып алуга, 1 кг тере авырлык ставкасы буенча;

д) терлекләрне ясалма орлыкландыру буенча оешмаларга – 1 доза өчен ставка буенча, сөт һәм ит юнәлешендәге нәселле үгезләр орлыкларын сатып алуга;

е) терлекләрне ясалма орлыкландыру буенча оешма булган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә – сөт һәм ит юнәлешендәге мөгезле эре терлек яралгыларын сатып алуга, шул исәптән импорт буенча, 1 данә исәбеннән ставка буенча.

8. Нәселле терлеккә ярдәм өчен, нәселле ана терлекләрне асрау өчен субсидияләр алу буенча авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) Министрлык тарафыннан расланган рәвештә белешмә-исәпләмә;

б) фермада терлек һәм кош-кортның хәрәкәте турында хуҗалык эче хисабы;

в) 2015 елга рәсми статистика хисабы өчен нигез булып торган терлекчелекнең торышы турында мәгълүмат;

г) үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза.

9. Сөт юнәлешендәге нәселле мөгезле эре терлек асрауга ярдәм өчен субсидияләр алу буенча, шул исәптән:

9.1. Сөт юнәлешендәге нәселле мөгезле эре терлекләрнең ана терлекләрен асрау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) Министрлык тарафыннан расланган рәвештә белешмә-исәпләмә;

б) фермада терлек һәм кош-кортның хәрәкәте турында хуҗалык эче хисабының күчермәсе;

в) 2015 елга рәсми статистика хисабы өчен нигез булып торган терлекчелекнең торышы турында мәгълүмат;

г) үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза.

9.2. Сөт юнәлешендәге нәселле үгез-җитештерүчләрне асрау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) Министрлык тарафыннан расланган рәвештә белешмә-исәпләмә;

б) фермада терлек һәм кош-кортның хәрәкәте турында хуҗалык эче хисабының күчермәсе;

в) 2015 елга рәсми статистика хисабы өчен нигез булып торган терлекчелекнең торышы турында мәгълүмат;

г) үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза.

9.3. Сөт юнәлешендәге нәселле үгез-җитештерүчеләрне, шул исәптән импорт буенча сатуп алуга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) Министрлык тарафыннан расланган рәвештә белешмә-исәпләмә;

б) товарлар өчен түләнгәнлеккә банктан өземтә һәм түләү поручениесе, түләүче банк раслаган аванс түләүләрен кертеп;

в) нәселле терлек үрчетүче оешма тарафыннан бирелгән шартнамә, счет-фактура, накладной яки гурт ведомосте, нәсел таныклыгы яки паспорт (ун баштан артыграк терлек сатып алынган очракта нәсел таныклыклары яки паспорт реестры тапшырыла);

г) фермада терлек һәм кош-кортның хәрәкәте турында хуҗалык эче хисабы;

д) 2015 елга рәсми статистика хисабы өчен нигез булып торган терлекчелекнең торышы турында мәгълүмат;

е) үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза.

9.4. Сөт юнәлешендәге мөгезле эре нәселле яшь терлек сатып алуга, шул исәптән импорт буенча, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) Министрлык тарафыннан расланган рәвештә белешмә-исәпләмә;

б) товарлар өчен түләнгәнлеккә банктан өземтә һәм түләү поручениесе, түләүче банк раслаган аванс түләүләрен кертеп;

в) нәселле терлек үрчетүче оешма тарафыннан бирелгән шартнамә, счет-фактура, накладной яки гурт ведомосте, нәсел таныклыгы яки паспорт (ун баштан артыграк терлек сатып алынган очракта нәсел таныклыклары яки паспорт реестры тапшырыла);

г) фермада терлек һәм кош-кортның хәрәкәте турында хуҗалык эче хисабы;

д) 2015 елга рәсми статистика хисабы өчен нигез булып торган терлекчелекнең торышы турында мәгълүмат;

е) үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза.

9.5. Сөт юнәлешендәге нәселле үгез-җитештерүчеләрне сатып алуга, шул исәптән импорт буенча, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) Министрлык тарафыннан расланган рәвештә белешмә-исәпләмә;

б) товарлар өчен түләнгәнлеккә банктан өземтә һәм түләү поручениесе, түләүче банк раслаган аванс түләүләрен кертеп;

в) товарлар өчен түләнгәнлеккә банктан өземтә һәм түләү поручениесе, түләүче банк раслаган аванс түләүләрен кертеп;

в) нәселле терлек үрчетүче оешма тарафыннан бирелгән шартнамә, счет-фактура, накладной яки гурт ведомосте, нәсел таныклыгы яки паспорт (ун баштан артыграк терлек сатып алынган очракта нәсел таныклыклары яки паспорт реестры тапшырыла);

г) фермада терлек һәм кош-кортның хәрәкәте турында хуҗалык эче хисабы;

д) 2015 елга рәсми статистика хисабы өчен нигез булып торган терлекчелекнең торышы турында мәгълүмат;

е) үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза.

9.6. Сөт юнәлешендәге нәселле үгез-җитештерүчеләрнең яралгыларын сатып алуга, шул исәптән импорт буенча, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) Министрлык тарафыннан расланган рәвештә белешмә-исәпләмә;

б) выписку из банка и платёжное поручение по оплате товаров, включая авансовые платежи, заверенные банком-плательщиком;

в) товарлар өчен түләнгәнлеккә банктан өземтә һәм түләү порučениесе, түләүче банк раслаган аванс түләүләрен кертеп;

в) нәселле терлек үрчетүче оешма тарафыннан бирелгән шартнамә, счет-фактура, накладной яки гурт ведомосте, нәсел таныклыгы яки паспорт (ун баштан артыграк терлек сатып алынган очракта нәсел таныклыклары яки паспорт реестры тапшырыла);

г) фермада терлек һәм кош-кортның хәрәкәте турында хуҗалык эче хисабы;

д) 2015 елга рәсми статистика хисабы өчен нигез булып торган терлекчелекнең торышы турында мәгълүмат;

е) үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза.

10. Ит юнәлешендәге нәселле мөгезле эре терлеккә ярдәм өчен субсидияләр алу буенча, шул исәптән:

10.1. Ит юнәлешендәге нәселле мөгезле эре терлекләрнең ана терлекләрен асрау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) Министрлык тарафыннан расланган рәвештә белешмә-исәпләмә;

б) фермада терлек һәм кош-кортның хәрәкәте турында хуҗалык эче хисабының күчермәсе;

в) 2015 елга рәсми статистика хисабы өчен нигез булып торган терлекчелекнең торышы турында мәгълүмат;

г) үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза.

10.2. Ит юнәлешендәге нәселле үгез-җитештерүчләрне асрау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) Министрлык тарафыннан расланган рәвештә белешмә-исәпләмә;

б) фермада терлек һәм кош-кортның хәрәкәте турында хуҗалык эче хисабының күчермәсе;

в) 2015 елга рәсми статистика хисабы өчен нигез булып торган терлекчелекнең торышы турында мәгълүмат;

г) үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза.

10.3. Ит юнәлешендәге нәселле үгез-җитештерүчеләрне, шул исәптән импорт буенча сатуп алуга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) Министрлык тарафыннан расланган рәвештә белешмә-исәпләмә;

б) товарлар өчен түләнгәнлеккә банктан өземтә һәм түләү поручениесе, түләүче банк раслаган аванс түләүләрен кертеп;

в) нәселле терлек үрчетүче оешма тарафыннан бирелгән шартнамә, счет-фактура, накладной яки гурт ведомосте, нәсел таныклыгы яки паспорт (ун баштан артыграк терлек сатып алынган очракта нәсел таныклыклары яки паспорт реестры тапшырыла);

г) фермада терлек һәм кош-кортның хәрәкәте турында хуҗалык эче хисабы;

д) 2015 елга рәсми статистика хисабы өчен нигез булып торган терлекчелекнең торышы турында мәгълүмат;

е) үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза.

10.4. Ит юнәлешендәге мөгезле эре нәселле яшь терлек сатып алуга, шул исәптән импорт буенча, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) Министрлык тарафыннан расланган рәвештә белешмә-исәпләмә;

б) товарлар өчен түләнгәнлеккә банктан өземтә һәм түләү поручениесе, түләүче банк раслаган аванс түләүләрен кертеп;

в) нәселле терлек үрчетүче оешма тарафыннан бирелгән шартнамә, счет-фактура, накладной яки гурт ведомосте, нәсел таныклыгы яки паспорт (ун баштан артыграк терлек сатып алынган очракта нәсел таныклыклары яки паспорт реестры тапшырыла);

г) фермада терлек һәм кош-кортның хәрәкәте турында хуҗалык эче хисабы;

д) 2015 елга рәсми статистика хисабы өчен нигез булып торган терлекчелекнең торышы турында мәгълүмат;

е) үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза.

10.5. Ит юнәлешендәге нәселле үгез-җитештерүчеләрне сатып алуга, шул исәптән импорт буенча, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) Министрлык тарафыннан расланган рәвештә белешмә-исәпләмә;

б) товарлар өчен түләнгәнлеккә банктан өземтә һәм түләү поручениесе, түләүче банк раслаган аванс түләүләрен кертеп;

в) нәселле терлек үрчетүче оешма тарафыннан бирелгән шартнамә, счет-фактура, накладной яки гурт ведомосте, нәсел таныклыгы яки паспорт (ун баштан артыграк терлек сатып алынган очракта нәсел таныклыклары яки паспорт реестры тапшырыла);

г) фермада терлек һәм кош-кортның хәрәкәте турында хуҗалык эче хисабы;

д) 2015 елга рәсми статистика хисабы өчен нигез булып торган терлекчелекнең торышы турында мәгълүмат;

е) үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү турында гариза.

Тапшырылган документларның күчермәләре авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан таныклана.

Министрлык:

а) субсидияләр алуга гаризаларны, алынган көнне, журналда терки, журнал битләренә номер сугылган һәм тегелгән, мөһер белән расланган, беркетелгән булырга тиеш;

б) бу Тәртипнең 8-10 пунктлары нигезендә тапшырылган документларны карап тикшерә. Документларны карап тикшерү срогы – гариза теркәтүгә алынганнан соң 15 эш көне.

Субсидия бирүдән баш тартуга түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларны тулысынча тапшырмау;

документларда тулы булмаган, ялган мәгълүматларның булу;

бюджет йөкләмәләре лимитының булмавы.

11. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм Федераль казначылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең лицевой счетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең расчет счетларына, акча акчаларын бирү турында карар кабул ителгәннән соң 10 эш көне эчендә, акча акчаларын күчерүне хәл итә.
Министрлык, Министрлык тарафыннан расланылган форма буенча, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән субсидия бирү турында килешү (алга таба – Килешү) төзи, анда субсидияләр бирүнең мәҗбүри шарты булып алучыларның Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары тарафыннан субсидияләр алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүгә ризалык бирүе тора.

12. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгән аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет керемнә кире кайтарылырга тиеш.

13. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан

соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.

14. Бу Тәртипнең 12 һәм 13 пунктларында күрсәтелгән бюджет акчаларын федераль бюджет кеременә ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

15. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

16. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык аларның җитәкчеләренә һәм баш бухгалтерларына йөкләнә. Закон бозучыларга карата закон нигезендә күздә тотылган җаваплылык чаралары кулланыла.

17. Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.